**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**


Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышев урамы, 23нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru


2022 елның «15» апреле 985 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһәре, О.Кошевой ур., 36 а йорт адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170140:19 5 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләү турында**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендәКАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһәре, О.Кошевой ур., 36 а йорт адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170140:195 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләүгә керешергә:.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2022 елның октябренә кадәр билгеләргә.

4. . Әлеге Карар басылып чыкканнан соң, физик һәм юридик затларга ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына проектны әзерләү тәртибе, сроклары, шулай ук проектны эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлегенә йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация четәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.А. Новиков**